ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

16.06.2021

№ 786

Сәламәтлек саклау хезмәткәрләренә
Алабуга муниципаль районы
Башлыгының исемле стипендиясен
билгеләү турында

Табиб-белгечләрнең һөнәри осталыгын стимуллаштыру, Алабуга муниципаль районы халкына медицина ярдәме күрсәтүнең сыйфатын яхшырту һәм табибларны социаль яклау максатларында Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Сәламәтлек саклау хезмәткәрләренә Алабуга муниципаль районы Башлыгының исемле стипендиясен билгеләү буенча комиссия составын төзергә һәм расларга (1 нче кушымта).

2. Сәламәтлек саклау хезмәткәрләренә Алабуга муниципаль районы Башлыгының исемле стипендиясен билгеләү комиссиясенең эше турындагы Нигезләмәне (2 нче кушымта) һәм сәламәтлек саклау хезмәткәрләренә Алабуга муниципаль районы Башлыгының исемле стипендиясен билгеләү турындагы Нигезләмәне (3 нче кушымта) расларга.

3. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (Садыйкова Э.И.) сәламәтлек саклау хезмәткәрләре өчен Алабуга муниципаль районы Башлыгының исемле стипендиясен бирү өчен ел саен акча бүлеп бирүне тәкъдим итәргә.

4. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Сәламәтлек саклау хезмәткәрләренә Алабуга муниципаль районы Башлыгының исемле стипендиясен билгеләү турында» 2016 елның 3 августындагы 975 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

5. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары Л.Р. Яһудинга йөкләргә.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
“ 886 ” 16.06.2024 ел

карарына 1 нче кушымта

## Сәламәтлек саклау хезмәткәрләренә Алабуга муниципаль районы Башлыгының исемле стипендиясен билгеләү буенча комиссия
## СОСТАВЫ

| № | Ф.И.А.и. | Вазифа атамасы |
|---|---|---|
| 1. | Яһудина Лилия Рәвил кызы | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары, комиссия рәисе |
| 2. | Сәфәров Рамил Рәфхәт улы | «Алабуга үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| 3. | Фатыйхова Джанетта Алексеевна | Баш табибның кадрлар буенча урынбасары, комиссия секретаре (килешү буенча) |
| Комиссия әгъзалары | | |
| 4 | Гайсин Азат Сөнәгат улы | «Алабуга үзәк район хастаханәсе» ДАССУ халыкка медицина хезмәте күрсәтү буенча баш табиб урынбасары (килешү буенча) |
| 5. | Садыйкова Эльмира Илдар кызы | Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча) |
| 6. | Нәҗметдинов Сәетнур Сәләхи улы | «Алабуга үзәк район хастаханәсе» ДАССУ медицина өлеше буенча баш табиб урынбаса ры (килешү буенча) |
| 7. | Гришина Людмила Александровна | «Алабуга үзәк район хастаханәсе» ДАССУ клиник-эксперт эше буенча баш табиб урынбасары (килешү буенча) |
| 8. | Солтанова Гөлнара Рәүф кызы | «Алабуга үзәк район хастаханәсе» ДАССУ балаларга һәм бала табуга ярдәм итү буенча баш табиб урынбасары (килешү буенча) |
| 9. | Ибраһимова Фәния Фәрит кызы | «Алабуга үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш икътисадчысы (килешү буенча) |

| | | |
|---|---|---|
| 10. | Сөләйманов Дамир Тәлгать улы | «Алабуга үзәк район хастаханәсе» ДАССУ поликлиника эше буенча баш табиб урынбасары (килешү буенча) |
| 11. | Резвякова Румия Рафкать кызы | Сәламәтлек саклау хезмәткәрләренең профсоюз комитеты рәисе (килешү буенча) |
| 12. | Кавиев Айрат Фәрхәт улы | АМР иҗтимагый советы рәисе ( килешү буенча) |

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
“ 786 ” 16.06.2021 ел
карарына 2 нче кушымта

**Сәламәтлек саклау хезмәткәрләренә Алабуга муниципаль районы Башлыгының исемле стипендиясен билгеләү комиссиясенең эше турында Нигезләмә**

1. Сәламәтлек саклау хезмәткәрләренә Алабуга муниципаль районы Башлыгының исемле стипендиясен билгеләү комиссиясе составы (алга таба комиссия), Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Алабуга үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы тәкъдиме нигезендә карар белән раслана.

2. Комиссиягә исемле стипендия билгеләүгә тәкъдим ителгән табибларның документларын кабул итү һәм карау бурычлары йөкләнә.

3. Исемле стипендия билгеләү комиссиясе әгъзалары өчен кирәкле документлар соратып ала.

4. Комиссия утырышында комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, ул тулы хокуклы дип санала.

5. Сәламәтлек саклау хезмәткәрләренә Алабуга муниципаль районы Башлыгының исемле стипендиясен билгеләү комиссиянең карарлары ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

Әгәр алар өчен утырышта катнашучы Конкурс комиссиясе әгъзаларының яртысыннан күбрәге (50 процентыннан күбрәге) тавыш бирсә, кабул ителгән булып санала.

6. Кабул ителгән карар «Алабуга үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибына һәм Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә раслауга тәкъдим ителә.

7. Сәламәтлек саклау хезмәткәрләренә Алабуга муниципаль районы Башлыгының исемле стипендиясен билгеләү өчен барлык материаллар түбәндәге адреска (тәкъдим ителә) җибәрелә:

423603 Алабуга, Нефтьчеләр проспекты, 57 йорт,
кадрлар бүлеге, тел.7-13-98 – 1нче майга кадәр.